## **ЯҢА ЕЛ ҖЫРЫ**

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Язлар, җәйләр аша үтеп, уңышлар җыеп,
Тагын бер ел узып китте, канатын җәеп.
Ел барышыннан калышмый без бардык атлап,
Дөрес яшәргә тырышып, сабырлык саклап.

**Кушымта:**

Уңышлы булсын дип җәйләр,
Ап-ак юрганнарын җәйгән
Яңа ел белән!
Яңа өметләр тудырган,
Һәр кешене куандырган
Яңа ел белән!

Яңа ел белән! Яңа ел белән!
Барчагызны да котлыйбыз
Яңа ел белән!

2. Без телибез бар яшьләргә саф, матур хисләр.
Беркайчан да керләнмәссен сезнең күңелләр!
Парлыларның мәхәббәте гомерлек булсын!
Парсызларга пар канатын табарга язсын!

**Кушымта.**

3. Без телибез балаларга шатлыклы җәйләр!
Газиз әткәй-әнкәйләргә – озын гомерләр!
Без телибез илебезгә иминлек-байлык!
Без телибез һәммәгезгә исәнлек-саулык!

**Кушымта.**

**Новогодняя песня**

*С Новым годом поздравляю,*
*Счастья и любви желаю*
*Я, друзья, нам всем!*

*Новый год пускай поможет*
*Нам найти решенье сложных,*
*Ключевых проблем!*

*Пусть он принесёт*
*Всем большой доход*
*И пусть добрым и удачным*
*Будет Новый год!*